ГЛАВА БАЙРЯКИ-ТАМАКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Байряки-Тамак, ул.Новая, д.37, ,
423964

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘЙРӘКӘ-ТАМАК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Бәйрәкә-Тамак авылы, Яңа урамы,
37 йорт, 423964

Тел.:(85593) 5-13-25, факс:5-13-24, e-mail: Btam.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

N 1 08.11.2022

Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегендә 2023 елда үзара салым кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003ел 6 октябрендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең 2019 елның 17 июлендәге 8 санлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниөипаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Уставының 14, 81 маддәләре, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкәтамак авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советының 2019 елның 10 сентябрендәге 11 санлы карары белән расланган Нигезләмә нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 19 ноябренә Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Бәйрәкәтамак авылы, Яңа урамы, 36 нчы йорт адресы буенча урнашкан КФҮ бинасы янында 9.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районыБәйрәкәтамак авыл җирлеге Бәйрәкәтамак авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Бәйрәкәтамак авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2023 елда үзара салым кертү турында килешәсезме, бары тик көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- Байрәкәтамак бистәсендә зират территориясен киртәләүне ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);

- чишмә территориясен төзекләндерү ( төзелеш материаллары сатып алу, каптажны ремонтлау, торбаларны алыштыру, покраска, шартнамә буенча эшләр өчен түләү), Бәйрәкәтамак бистәсендә;

-җирлек юлларын карап тоту (юлларны кардан чистарту, шартнамә буенча эшләр өчен түләү)

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы” на веб-адрес буенча урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru; Ютазы муниципаль районының веб-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында веб-адрес буенча: www.yutaza.tatar.ru кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә.

4. Әлеге карар басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

"Бәйрәкәтамак авыл җирлеге"
муниципаль берәмлеге башлыгы Ф.В.Әхмәтов